КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 17 декабрь г.Казань № 1157

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү буенча «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

1.1 нче пунктта «2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү буенча «Яңа туган балага бүләк» акциясен Татарстан Республикасы территориясендә тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү механизмын билгели» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган яңа туган балалы

гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү буенча «Яңа туган балага бүләк» акциясен 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү механизмын билгели» сүзләренә алыштырырга;

2.2 нче пунктта «биш календарь көннән дә» сүзләрен «дүрт календарь көннән дә» сүзләренә алыштырырга;

2.4 нче пунктның дүртенче абзацында «вакыты чыккан» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.9 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«субсидия алучының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана торган Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итүне оештыру мәсьәләләре буенча ведомствоара хезмәттәшлек регламентын үтәүгә йөкләмәсе;»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итүне оештыру мәсьәләләре буенча ведомствоара хезмәттәшлек регламентында:

3.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2020 елның гыйнварында Татарстан Республикасы медицина оешмаларын бүләк комплектлары белән кирәкле санда тәэмин итү өчен заявка Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан субсидия алучы турында мәгълүмат алган көннән өч көн эчендә бирелә.»;

3.5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2020 елның гыйнварында Татарстан Республикасы медицина оешмаларын бүләк комплектлары белән кирәкле санда тәэмин итү өчен субсидия алучы Татарстан Республикасы медицина оешмаларына бүләк комплектларын Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы заявкасында күрсәтелгән вакытта алып килүне гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин